КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 июль г.Казань № 601

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 4 август, 566 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 241 нче; 2017 ел, 28 июнь, 450 нче; 2018 ел, 26 июнь, 520 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

1 нче пунктта «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы (алга таба – Программа) |
| Төбәк программасын эшләү турында карар кабул итү датасы, аны раслау датасы (тиешле норматив актның исеме һәм номеры) | Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;<br>«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе;<br>Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Программаның дәүләт заказчысы – координаторы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗәни исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе галимнәренең эшче төркеме |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максатлары – Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм |

| | |
|---|---|
| | тел күптөрлелеген саклау һәм ярдәм итү, чит ил гражданнарын Россия җәмәгатьчелегенә уңышлы социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген ныгыту.<br>Программаның бурычлары:<br>1. Гражданнарның тигез хокуклылыгын һәм аларның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.<br>2. Милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүне тәэмин итү.<br>3. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм рухи үсешенә, Россия җәмгыяте нигезләре буларак традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген ныгытуга ярдәм итү.<br>4. Ватаныбыз тарихы өчен гражданлык үзаңын, ватанпәрвәрлекне, гражданлык җаваплылыгын, горурлык хисен формалаштыру, милләтара аралашу мәдәниятен тәрбияләү.<br>5. Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм яклау.<br>6. Чит ил гражданнарын (мигрантларны) социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү системасын камилләштерү.<br>7. Дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү, шул исәптән Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү.<br>8. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү |
| Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре | Татарстан Республикасында милләтара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяли торган республика халкы өлеше;<br>Татарстан Республикасында конфессияара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяли торган республика халкы өлеше;<br>башка милләт вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәт дәрәҗәсе;<br>гомумроссия гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсе;<br>Татарстан тәңгәллеге дәрәҗәсе;<br>үз-үзенә карата милли билге буенча дискриминация булмавын билгеләп үтүче гражданнар өлеше;<br>чит ил гражданнарына (мигрантларга) тискәре мөнәсәбәт кичерми торган гражданнар өлеше;<br>гражданнар бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара |

| | |
|---|---|
| | мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшь кешеләр саны;<br>Россия халыкларының этномәдәни үсешенә һәм тел күптөрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшь кешеләре саны;<br>Рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны;<br>Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсендәге проектларны һәм программаларны тормышка ашыру барышында кулланыла торган халыкларның телләре саны;<br>милли-рухи-агарту эшчәнлеге өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмалар үткәргән чаралар саны;<br>мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны;<br>Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өчен җаваплы, өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укыган дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр саны;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданлык бердәмлеген саклауга һәм этникара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән программаны тормышка ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре саны |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2023 еллар, шул исәптән:<br>I этап: 2014 – 2016 еллар;<br>II этап: 2017 – 2023 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 471,2505 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 39,324 млн.сум;<br>2015 елда – 32,724 млн.сум;<br>2016 елда – 42,624 млн.сум;<br>2017 елда – 40,371 млн.сум;<br>2018 елда – 52,2787 млн.сум;<br>2019 елда – 53,6144 млн.сум;<br>2020 елда – 56,6386 млн.сум;<br>2021 елда – 48,2286 млн.сум;<br>2022 елда – 55,7786 млн.сум;<br>2023 елда – 49,6686 млн.сум.<br>2014 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 21,6008 млн.сум тәшкил итә. |

| | |
|---|---|
| | 2015 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 17,96775 млн.сум тәшкил итә.<br>2016 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 18,2494 млн.сум тәшкил итә.<br>2017 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 9,1068 млн.сум тәшкил итә.<br>2018 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,3585 млн.сум тәшкил итә.<br>2019 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,8317 млн.сум тәшкил итә.<br>2020 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,5074 млн.сум тәшкил итә.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш»; |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Татарстан Республикасында милләтара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяли торган республика халкы өлеше 79 процентка җитәчәк;<br>Татарстан Республикасында конфессияара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче республика халкы өлеше – 82,9 процентка;<br>башка милләт вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәт дәрәҗәсе – 95 процентка;<br>гомумроссия гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсе – 79 процентка;<br>Татарстан тәңгәллеге дәрәҗәсе – 79 процентка;<br>үз-үзенә карата милли билге буенча дискриминация булмавын билгеләп үтүче гражданнар өлеше – 93,5 процентка;<br>чит ил гражданнарына (мигрантларга) тискәре мөнәсәбәт кичерми торган гражданнар өлеше – 75,5 процентка;<br>гражданнар бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 70 200 кешегә, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшь кешеләр – 49 120 кешегә;<br>Россия халыкларының этномәдәни үсешенә һәм тел күптөрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 556 000 кешегә, шулардан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшь кешеләре – 164 000 кешегә;<br>Рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 131 480 кеше;<br>Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсендәге проектларны һәм программаларны тормышка ашыру барышында кулланыла торган халыкларның телләре саны – |

| | |
|---|---|
| | 37гә;<br>милли-рухи-агарту эшчәнлеге өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмалар үткәргән чаралар саны – 1 850гә;<br>мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны – 4 050 кешегә;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданлык бердәмлеген саклауга һәм этникара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән программаны тормышка ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре саны – кимендә 100гә;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданлык бердәмлеген саклауга һәм этникара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән программаны тормышка ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре саны – 45кә»; |

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның максатлары, бурычлары, максатларына ирешү һәм бурычларны хәл итү сроклары (этаплары) һәм күрсәткечләре (индикаторлары)

Программаның максатлары һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясенең һәм Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясенең төп нигезләмәләренә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсен җайга сала торган башка норматив хокукый актларга бәйле.

Программаның максатлары – Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларны уңышлы социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү.

Куелган максатларга ирешү түбәндәге бурычларны тормышка ашыруны күздә тота:

1. Гражданнарның тигез хокуклылыгын һәм аларның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

2. Милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләш-терүне тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм рухи

үсешенә, Россия җәмгыяте нигезләре буларак традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген ныгытуга ярдәм итү.

4. Ватаныбыз тарихы өчен гражданлык үзаңын, ватанпәрвәрлекне, гражданлык җаваплылыгын, горурлык хисен формалаштыру, милләтара аралашу мәдәниятен тәрбияләү.

5. Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм яклау.

6. Чит ил гражданнарын (мигрантларны) социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү системасын камилләштерү.

7. Дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү, шул исәптән Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү.

8. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2023 еллар.

Программаны гамәлгә ашыру ике этапта башкарыла:

I этап (2014 – 2016 еллар). I этапның максаты – Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү өлкәсендә уңай алга китешләрне формалаштыру.

Беренче этапта каралган:

патриотизм һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген формалаштыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән комплекслы мәгълүмати кампанияне үткәрү һәм мәгълүмати ресурслар булдыруга юнәлтелгән мәгълүмат ресурслары булдыру;

патриотизм һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген формалаштыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларга һәм чараларга ярдәм итү;

низаглы хәлләр турында мәгълүматны кабул итү буенча call-үзәк булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә тенденцияләрнең торышын һәм тенденцияләрен билгеләү максатларында социологик тикшеренүләр үткәрү;

этнополитик һәм дини-сәяси экстремизм, ксенофобия һәм түземсезлек профилактикасы.

II этап (2017 – 2023 еллар). II этапның максаты – I этапта барлыкка килгән уңай тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту, шул исәптән Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү өлкәсендә тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешү.

II этапта дәүләт милли сәясәте өлкәсендә чараларны, шул исәптән дәүләт милли сәясәте өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итү каралган:

мигрантларны адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чаралар һәм инициативаларны үтәү;

милләтара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм милләтара низагларны иртә кисәтү системасын булдыру һәм алып бару;

Россия халыклары турында белемнәрне таратуга юнәлдерелгән белем бирү чараларын тормышка ашыру;

гомумгражданлык бердәмлеге һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү мәсьәләләре компетенциясендә булган дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү.

Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Программаның максатчан индикаторлары һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре кулланыла.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программа чаралары

Программа максатларына һәм бурычларына ирешү өчен, аны тормышка ашыруның барлык юнәлешләре буенча формалашачак.

Милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглауның ведомствоара системасын оештыру;

дини һәм милли нигездә низаглы хәлләр турында мәгълүматны кабул итү буенча call-үзәк булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру;

мәдәният хезмәткәрләренең милләтара низагларны кисәтү буенча киңәшмәләрен үткәрү;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү темасын яктырта торган социаль роликлар булдыру;

«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү;

«Этнобъектив» республика акциясен (этнофотокроссын) оештыру һәм үткәрү;

«Күпьяклы Татарстан» күчмә фотокүргәзмәсен оештыру;

Халыкара яһүд музыкасы фестивален үткәрү;

Беларусь һәм Россия халыкларының бердәмлеге көненә багышланган чаралар үткәрү.

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм рухи үсешенә ярдәм итү, Россия җәмгыяте нигезе буларак традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген ныгыту буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру ярдәмендә ирешелә:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә хаҗ кылу, этник, гастрономик һәм экологик туризмны үстерү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли спорт төрләре буенча ел саен уздырыла торган фестивален (спартакиадасын), традицион уеннарын һәм

уен-көлкеләрен оештыру һәм үткәрү;

И.Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын үткәрү;

«Иман музыкасы» халыкара рухи музыка фестивален үткәрү;

«Крутушка» халыкара этник фестивален үткәрү;

«Түгәрәк уен» («Игра в кругу») бөтенроссия татар фольклоры фестивален үткәрү;

Бөтенроссия Спас ярминкәсен үткәрү;

Чуваш җырын башкаручыларның «Чуваш сандугачы» республика конкурсын үткәрү;

«Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестивален үткәрү;

Фин-угор халыкларының республика фестивален үткәрү;

Халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать республика яшьләр фестиваль-конкурсын үткәрү;

«Мәдәниятләр мозаикасы» республика этноконфессиональ фестивален үткәрү;

Керәшен җырын яшь башкаручыларының «Туым жондызы» («Рождественская звезда») республика конкурс-фестивален үткәрү;

Туган тел көнен (26 апрель), Рус теле көнен (6 июнь), Татарстан Республикасы көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар планын әзерләү һәм тормышка ашыру;

казак җырларының ачык конкурс-фестивален оештыру һәм үткәрү. «Казачий круг» бөтенроссия фольклор конкурсында катнашу;

Балалар фольклор коллективларының «Звонкая капель – Моңлы тамчы» республика фестивален оештыру һәм үткәрү;

«Широкая Масленица» республика бәйрәмен оештыру һәм үткәрү;

«Алмалы Спас» районара халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү;

«Троицкие напевы» рухи җыр фестивален оештыру һәм үткәрү;

«Нәүрүз» төрки халыклар бәйрәмен үткәрү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның түбәндәге бәйрәмнәрен үткәрү: «Сабантуй», «Каравон», «Уяв», «Семык», «Гырон быдтон», «Учук», «Балтай», «Иван Купала», «Питрау» һ.б.

Гражданлык үзаңын, ватанпәрвәрлекне, гражданлык җаваплылыгын, Ватаныбыз тарихы өчен горурлык хисен формалаштыру, милләтара аралашу мәдәниятен тәрбияләү буенча Программада куелган бурычларны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

«Минем йорт – минем республика» яшьләр чатыр мәдәниятләр һәм диалог паркы эшен оештыру;

Халыклар бердәмлеге көненә багышланган тантаналы чара үткәрү;

балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәниятенә, тридицияләренә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт рухында балаларны һәм яшүсмерләрне тәрбияләү буенча нәтиҗәле тәҗрибәләр конкурсын үткәрү;

мәктәпкәчә, урта гомуми, һөнәри, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү белгечләре өчен «Мәдәниятләр диалогы» мәдәни-мәгариф проектын гамәлгә ашыру;

Казан шәһәрендә чит илләрдә яшәүче Россия ватандашларының бөтендөнья яшьләр форумын үткәрү;

«Дөньяның барлык буяулары» республика ирекләләр проектын гамәлгә ашыру;

яшьләрнең герой шәһәрләр һәм хәрби дан шәһәрләрендә, Россия халыкларының мәдәни мирас объектларында (тарих һәм мәдәният ядкәрләрендә) булуын оештыру;

«Халыклар дуслыгы – Татарстан байлыгы» республика яшьләр халыкара форумын оештыру һәм үткәрү;

«Татар яшьләре көннәре» халыкара форумын һәм иҗади балалар һәм яшьләр өчен «Дулкыннар» («Волны») республика конкурсын үткәрү;

«Татарстан халыклары кухнясы» төбәкара конкурс-фестивален үткәрү;

студентларның хезмәт (археологик) отрядлары эшен оештыру һәм Татарстан Республикасында тарих һәм мәдәният ядкәрләрен торгызу эшенә яшьләрнең ирекләләр хәрәкәтен җәлеп итү, эшләр үткәрелә торган урыннарда студентларның, яшь галимнәрнең, мәктәп укучыларының һәм туган якны өйрәнүчеләрнең тарихый-этнологик һәм этносәяси җыеннарын һәм конференцияләрен үткәрү юлы белән аларны популярлаштыру.

Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле буларак рус телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм яклау буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

Кирилл-Мефодий яшүсмерләр укуларын оештыру һәм үткәрү;

«Татарстан Республикасының рус традицион мәдәнияте» республика проектын тормышка ашыру;

Татарстан Республикасында рус теле буенча халыкара тоталь диктант оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм итү;

Туган (рус булмаган) теле булган мәктәпләрдә укучылар өчен рус теле буенча халыкара олимпиада оештыру һәм үткәрү;

Татар теле буенча халыкара олимпиада оештыру һәм үткәрү;

балалар һәм яшьләр өчен «Милләтебез хәзинәләре» – «Сокровища нации» тел профильле сменасын оештыру һәм үткәрү;

халыклар дуслыгының югары уку йортлары арасында студентлар фестивален үткәрү;

туган (чуваш, удмурт, мари, мордва) телләр һәм әдәбиятыннан мәктәп укучыларының республика олимпиадасын оештыру һәм үткәрү;

«Радуга – Салават күпере» республика балалар-яшүсмерләр милли мәдәниятләр фестивален үткәрү;

күпмилләтле якшәмбе мәктәпләренең һәм этномәдәни компонентлы мәктәпләрдә укучыларның фестивален (слетын) үткәрү;

Туган телләр укытучыларының бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү;

Татарстан Республикасында челтәрле полилингваль белем бирү комплекслары эшчәнлеген оештыру;

Россия халыкларының әдәбият әсәрләрен татар һәм рус телләренә тәрҗемәләрен әзерләү һәм бастырып чыгару.

Чит ил гражданнарын (мигрантларны) социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү системасын камилләштерү буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

мигрантлар өчен Россия тарихы һәм Россия Федерациясе законнары буенча укыту-методик комплектлар (пособиеләр) эшләү;

мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (ориентация) курсларны үткәрү чараларын гамәлгә ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга – бу иҗтимагый файдалы хезмәтне башкаручыларга «социаль һәм мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү һәм рус телен өйрәтү максатларында мигрантларга консультация бирү» иҗтимагый-файдалы хезмәт күрсәтү кысаларында кереш (ориентация) курсларын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр рәвешендә грантлар бирү;

Татарстан Республикасы икътисады белән таләп ителә торган чит ил эшче көчен җәлеп итү, сайлап алу һәм аннан файдалану механизмнарын камилләштерү;

«Дөнья энҗе бөртеге» студентлар фестивален, югары уку йортлары арасындагы «Чит ил студенты көне» фестивален оештыру һәм үткәрү;

Татарстан Республикасы мигрантларының этник диаспорасына һәм бергәлекләренә аларның адаптациясе һәм интеграциясенең гомуми дәрәҗәсен билгеләү, тормышта потенциаль һәм реаль конфликтоген һәм тотрыксызландыру факторларын ачыклау буенча комплекслы тикшерүне оештыру.

Дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү, шул исәптән Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмат белән тәэмин итү буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру ярдәмендә ирешелә:

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләре торышы һәм үсеше мониторингы; Татарстан Республикасында тел ситуациясенә фәнни тикшеренүләр үткәрү;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышының төп характеристикалары (индикаторлары) системасын эшләү һәм раслау;

дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, милли берләшмәләр һәм дини оешмалар белән үзара бәйләнешне гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре өчен укыту программаларын оештыру;

дәүләт милли сәясәтенең һәм дәүләт-конфессияләр мөнәсәбәтләренең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасында муниципаль районнарның авыл җирлекләре башлыклары өчен укыту семинарларын оештыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның бердәмлеген тәшкил итүче тарихи даталарны популярлаштыру буенча фәнни тикшеренүләрне оештыру, белем бирү проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Рес-

публикасында яшәүче халыкларның берләшүе факторы булган тарихи даталарны киң яктыртуны тәэмин итү;

«Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә этносоциаль һәм этномәдәни процессларны җайга салуның уңай тәҗрибәсе» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен үткәрү;

Милли массакүләм мәгълүмат чаралары форумын үткәрү;

Татарстан халыклары ассамблеясенең «Безнең йорт – Татарстан» журналына ярдәм итү;

Татарстан халыклары Ассамблеясы һәм Татарстан халыклары Дуслыгы Йорты сайтын www.addnt.ru мәгълүмат белән тәэмин итү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия һәм Татарстан мөселманнарының традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалауга юнәлдерелгән, диннәр арасындагы татулык һәм үзара хөрмәтнең тарихи тәҗрибәсенә таянып, максатчан эш оештыру;

Татарстан Республикасында яшәүче төрле халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыра торган һәм милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән теле- һәм радиотапшырулар циклын төзү;

«Күпьяклы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсын үткәрү;

массакүләм мәгълүмат чараларында милләтара һәм дәүләт-конфессияләр мөнәсәбәтләре мәсьәләләрен яктырту мәсьәләләре буенча журналистлар өчен Республика гамәли-юнәлешле семинарын үткәрү;

Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен иң яхшы яктырту буенча республика журналистлар конкурсын оештыру;

Россия җәмгыятенең милләтара һәм конфессияара күптөрлелеге мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында дөрес яктырту нигезләре буенча журналистлар өчен гамәли җитәкчелек эшләү һәм тарату;

югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе каршындагы иҗтимагый-сәяси һәм этноконфессиональ мәсьәләләр буенча эксперт советы эшчәнлеген формалаштыру һәм оештыру;

«Идел буе республикаларының милли әдәбияты: мәдәниятара багланышлар проблемалары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясен үткәрү;

«Россия төбәкләрендә этникара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүдә милли-мәдәни автономиянең роле һәм урыны» халыкара конференциясен Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясе һәм югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе базасында үткәрү;

«Саннар һәм фактлар» Татарстан халыклары турындагы җыентыгын бастырып чыгару;

«Милли сорау һәм җавап» проекты телетапшырулар циклын оештыру һәм булдыру.

Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен тормышка ашыру буенча программалар эшләү һәм кабул итү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни автономияләре җитәкчеләренең Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыруда катнашу мәсьәләсе буенча республика киңәшмәсен үткәрү;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтүне оештыру;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый советның милли-мәдәни үзәкләр эшчәнлеге мәсьәләләре буенча утырышын үткәрү;

милли-мәдәни берләшмәләр җитәкчеләре өчен дәүләт милли сәясәтенең актуаль мәсьәләләре һәм коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча укыту программаларын оештыру.

Әлеге юнәлешләргә караган чараларны башкаручыларны билгеләү дәүләт заказчылары тарафыннан дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

Программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Программада программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджеттан тыш акча (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасын) һәм муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 471,2505 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 39,324 млн.сум;
2015 елда – 32,724 млн.сум;
2016 елда – 42,624 млн.сум;
2017 елда – 40,371 млн.сум;
2018 елда – 52,2787 млн.сум;
2019 елда – 53,6144 млн.сум;
2020 елда – 56,6386 млн.сум;
2021 елда – 48,2286 млн.сум;
2022 елда – 55,7786 млн.сум;
2023 елда – 49,6686 млн.сум.

2014 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 21,6008 млн.сум тәшкил итә.

2015 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 17,96775 млн.сум тәшкил итә.

2016 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 18,2494 млн.сум тәшкил итә.

2017 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 9,1068 млн.сум тәшкил итә.

2018 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,3585 млн.сум тәшкил итә.

2019 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,8317 млн.сум тәшкил итә.

2020 елда Россия Федерациясе бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслау күләме 10,5074 млн.сум тәшкил итә.»;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 1.1 нче кушымтада:

башисемдә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

исемендә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

беренче абзацта «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 һәм 11 нче пунктларны өстәргә:

«10. Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни үсешенә һәм тел күптөрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашкан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны ($И_{10}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$И_{10} = \sum_i N_i^{МЭЯ},$$

монда $N_i^{МЭЯ}$ – Программа кысаларында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни үсешенә һәм тел күптөрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашкан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны.

11. Гражданлык бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән чараларда катнашкан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны ($И_{11}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$И_{11} = \sum_i N_i^{МЭО},$$

монда $N_i^{МЭО}$– Программа кысаларында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни үсешенә һәм тел

күптөрлелегенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашкан 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны.»;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 3 нче кушымтада:

башисемдә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

исемендә «2014 – 2022» саннарын «2014 – 2023» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин